ТАТАРТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**«“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Ә.С. Гыйниятуллин шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

Казан шәһәре 2019 елның 10 июле

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин Ә.С. Гыйниятуллин шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Ә.С. Гыйниятуллин «“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) 1 статьясындагы 2 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Әлеге Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлеше нигезендә «Хезмәт ветераны» исеме бирелү хокукын бирә торган ведомство аерымлык тамгалары дигәндә, федераль башкарма хакимият органнары, башка федераль дәүләт органнары, дәүләт корпорацияләре тарафыннан гамәлгә куелган һәм алар белән бүләкләү күрсәтелгән органнар һәм оешмалар

билгеләгән тәртиптә башкарылган, эштәге (хезмәттәге) казанышлар һәм эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә (икътисад тармагында) кимендә 15 ел дәвамында эшләгән (хезмәт иткән) өчен ведомство бүләкләре дип аңларга кирәк.

Шикаятьтән һәм аңа кушып бирелгән документлар күчермәләреннән күренгәнчә, гражданин Ә.С. Гыйниятуллин Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының Федераль медик-биологик агентлыгының 2016 елның 5 маендагы боерыгы нигезендә «Донорлык хәрәкәтенә ярдәм өчен» медале белән бүләкләнгән. Мөрәҗәгать итүче билгеләп үткәнчә, әлеге ведомство аерымлык тамгасы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 29 июнендәге 481 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында «Хезмәт ветераны» исемен биргәндә исәпкә алына торган хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары исемлегенә керә. Шуңа бәйле рәвештә ул күрсәтелгән министрлыкка үзенә «Хезмәт ветераны» исемен бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән. Әмма ул кан хезмәте оешмалары, сәламәтлек саклау идарәсе органнары хезмәткәре булмаганлыктан, ә күрсәтелгән медаль белән актив тормыш позициясе, донорлыкны пропагандалау һәм донорлар хәрәкәтен үстерүгә зур шәхси өлеш керткән өчен бүләкләнгән дип, документларны кабул итүдән баш тартылган.

Баш тарту белән килешмичә, «Хезмәт ветераны» исемен бирү хокукын тану турында әлеге министрлыкка дәгъва белән гариза бирүче Казан шәһәре Яңа Савин район судына мөрәҗәгать иткән. Татарстан Республикасы Югары суды граждан эшләре буенча суд коллегиясенең апелляция билгеләмәсе белән үзгәрешсез калдырылган карар нигезендә мөрәҗәгать итүчегә дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тартылган. Татарстан Республикасы Югары суды судьясы билгеләмәсе белән аның бу карарларга кассация шикаятен тапшырудан да шулай ук баш тартылган.

Шул ук вакытта ул дәгъва белдерелә торган нормада беркетелгән «федераль башкарма хакимият органнары, башка федераль дәүләт органнары,

дәүләт корпорацияләре тарафыннан гамәлгә куелган һәм аларны бүләкләү күрсәтелгән органнар һәм оешмалар тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башкарылган», дигән формулировка аның конституциячел хокукларын бозуга китергән, дип күрсәтә, чөнки ул «Хезмәт ветераны» исемен бары тик бүләкләүне гамәлгә ашырган органнарда эшләгән затларга гына бирүне күздә тота. Шул ук вакытта Федераль медицина-биология агентлыгының 2010 елның 24 мартындагы 155 номерлы боерыгы белән расланган «Донорлык хәрәкәтенә ярдәм өчен» медале турындагы нигезләмә эш урыннарына карап бүләкләнүчеләрнең хокукларын чикләүне күздә тотмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин Ә.С. Гыйниятуллин Татарстан Республикасы Конституция судыннан «“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешен Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28, 29 (беренче өлеш), 54 (беренче һәм икенче өлешләр) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясендә ветераннарны социаль яклауның хокукый гарантияләре «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон белән (алга таба шулай ук — Федераль закон) билгеләнгән.

Әлеге Федераль законның 7 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасы нигезендә СССР яки Россия Федерациясе орденнары яисә медальләре белән бүләкләнгән, я СССР яисә Россия Федерациясенең мактаулы исемнәренә лаек булган, я Россия Федерациясе Президентының мактау грамоталары белән бүләкләнгән яисә Россия Федерациясе Президенты рәхмәтенә лаек булган, я эштәге (хезмәттәге) казанышлар һәм эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә (икътисад тармагында) кимендә 15 ел дәвамында эшләгән (хезмәт иткән) өчен ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләнгән һәм пенсия билгеләү өчен ирләргә кимендә 25 ел һәм хатын-кызларга кимендә 20 ел итеп исәпләнә торган хезмәт (иминият) стажы яисә календарь буенча исәпләгәндә тиешле

еллар эшләгәнгә пенсия билгеләү өчен кирәкле тиешле эшләгән еллары булган затлар; хезмәт эшчәнлеген Бөек Ватан сугышы чорында балигъ булмаган яшьтә башлаган һәм ирләр өчен кимендә 40 ел һәм хатын-кызлар өчен кимендә 35 ел хезмәт (иминият) стажы булган затлар хезмәт ветераннары була. Шул ук вакытта аталган статьяның 1.1 пункты нигезендә «Хезмәт ветераны» исеме бирелү хокукын бирә торган ведомство аерымлык тамгаларын гамәлгә кую тәртибе эшчәнлеге белән Россия Федерациясе Хөкүмәте җитәкчелек итә торган федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан билгеләнә һәм күрсәтелгән аерымлык тамгалары белән бүләкләү Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә; «Хезмәт ветераны» исеме бирелү хокукын бирә торган ведомство аерымлык тамгаларын, башка федераль дәүләт органнары, дәүләт корпорацияләре тарафыннан гамәлгә кую һәм күрсәтелгән аерымлык тамгалары белән бүләкләү тәртибе, Россия Федерациясе законнарында башкача билгеләнмәгән булса, күрсәтелгән органнар, оешмалар тарафыннан билгеләнә.

Гражданин Ә.С. Гыйниятуллин шикаять белдерә торган норма үзенең эчтәлеге буенча да, хокукый мәгънәсе буенча да Федераль закон нигезләмәләренә бәйләнгән, аңа туры килә һәм федераль закон чыгаручы тарафыннан каралган «Хезмәт ветераны» исеме бирелергә мөмкин булган затлар категориясен билгеләүдән аерылып торучы үз карашын билгеләми.

Шулай итеп, гражданин Ә.С. Гыйниятуллин тарафыннан карала торган «“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенең конституциячеллеген тикшерү «Ветераннар турында» Федераль закон нормаларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәүләренә бәя бирүне аңлатыр иде, бу исә Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Ә.С. Гыйниятуллин шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки анда куелган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин Ә.С. Гыйниятуллинга һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

**№ 22-О**

**Татарстан Республикасы Конституция суды**